КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 март г.Казань № 193

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазы һәм инвентаре сатып алу буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазы һәм инвентаре сатып алу буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 2 март, 193 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең
спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазы һәм
инвентаре сатып алу буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында
Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы
муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга физик мәдәниятне һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карары белән расланган «2019 – 2024 елларга физик мәдәниятне һәм спортны үстерү» дәүләт программасы кысаларында спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазы һәм инвентаре сатып алу буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең (алга таба – муниципаль берәмлекләр) чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Субсидияләр бу Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында субсидияләр бүлү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.

Субсидияләрне финанслар белән тәэмин итү чыганагы – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Физик культураны һәм спортны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2021 елның 30 сентябрендәге 1661 номерлы карары белән расланган спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазы һәм инвентаре сатып алу өлешендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программалары чараларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен федераль бюджеттан Республика Татарстан Республикасы бюджетына кергән субсидияләр.

5. Субсидия бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийлары – муниципаль берәмлек территориясендәспортның база олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия төрләре буенча спорт әзерлегенең федераль стандартлары һәм спорт

әзерлеге программалары нигезендә җирле бюджет акчасы исәбеннән спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар булу.

6. Субсидия түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

муниципаль берәмлектә финанслашу максатларында субсидияләр бирелә торган, аларны тормышка ашырганда муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләре барлыкка килә торган чаралар исемлеге каралган хокукый акт, шул исәптән муниципаль программа булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидияләр бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре кирәкле күләмдә булу;

Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары арасында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү турында» 2014 елның 30 сентябрендәге 999 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр бирү турында килешү төзү;

тиешле финанс елында муниципаль берәмлектә олимпия резервындагы спорт мәктәпләре булу: 2022 һәм 2023 елларда – кимендә 7, 2024 һәм 2025 елларда – кимендә 3, 2026 елдан һәм аннан соңгы елларда – кимендә 1.

7. Субсидияләр Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып әзерләнә (формалаштырыла) һәм төзелә торган субсидияләр бирү турындагы килешү нигезендә бирелә.

Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен субсидия акчасы исәбеннән финанслашу дәрәҗәсе муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләреннән 81 процент тәшкил итә.

8. Муниципаль берәмлек бюджетына субсидия күләме ($C_{moi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{moi} = N_i \times H_{mo},$$

монда:

$N_i$ – бу Тәртипнең 6 пунктындагы бишенче абзацы нигезендә i-муниципаль берәмлекнең олимпия резервындагы спорт мәктәпләре саны;

$H_{mo}$ – муниципаль берәмлекнең олимпия резервындагы бер спорт мәктәбенә субсидия күләме.

Муниципаль берәмлекнең олимпия резервындагы бер спорт мәктәбенә субсидия күләме ($H_{mo}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Н_{mo} = \frac{С_{об}}{Н_{moi}},$$

монда:

$С_{об}$ – агымдагы финанс елында субсидияләр бирү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме;

$Н_{moi}$ – муниципаль берәмлекләрдә олимпия резервындагы спорт мәктәпләре саны.

9. Муниципаль берәмлек бюджетының субсидияләр исәбеннән финанслаша торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме, килешүдә билгеләнгән субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү зарурлыгыннан чыгып, муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар белән раслана (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлеге белән билгеләнә).

10. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең килешүдә билгеләнгән күрсәткечләрен фактта ирешелгән күрсәткечләре белән чагыштырып гамәлгә ашырыла.

11. Субсидияләрдән файдалану нәтиҗәләре:

олимпия резервындагы спорт мәктәпләре өлешендә барлык спорт әзерлеге оешмалары халыкка спортның база төрләре буенча спорт әзерлегенең федераль стандартлары һәм программалары нигезендә, спорт әзерлегенең федераль стандартларына таянып, хезмәт күрсәтә;

яңа спорт җиһазы һәм инвентаре кайтартылган олимпия резервындагы спорт мәктәпләре өлешендә спорт әзерлеге оешмалары саны.

12. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары Министрлыкка Килешүдә каралган форма, сроклар һәм тәртип буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган муниципаль берәмлекләр бюджетлары чыгымнары һәм субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре мәгънәләре турында хисаплар тапшыра.

13. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидиянең максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

14. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетларына субсидия күчерү Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына гамәлгә ашырыла.

15. Хисап финанс елыннан соң килә торган финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган субсидия агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

16. Субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемена күчерелмәгән очракта, әлеге акча Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена түләтелергә тиеш.

17. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән

субсидия акчасы Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган бюджетка мәҗбүри түләтү чаралары кулланыла.

18. Субсидияләрдән максатчан файдалануны, субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүдә тоту Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.